# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең Ольгино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 ноябрендәге 3 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү хакында

02 апрель 2024 ел. № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 02 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең Ольгино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 21 ноябрендәге 3 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә ризамы: дигән сорауны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Ольгино авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Әфганстанда, Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, түләү кләме 350 ( өч йөз илле сум) сум итеп билгеләнгән көндезге уку формасындагы студентлардан, мобилизацияләнгән һәм ЛХР һәм ДХРда махсус хәрби операция кысаларында контракт төзегән гражданнардан, шулай ук аларның тормыш иптәше, балигъ булган балалары, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 700 ( жиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтү белән сез килешәсезме»:

**1. Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Ольгино авылы буенча урамнарны яктырту, Ольгино авылының Набережная урамы яктырткычларын алмаштыру;
- яктырткычлар сатып алу.

**2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:**

- Ольгино авылының Набережная урамында автомобиль юлларын кышкы карап тоту;
- Ольгино авылының Набережная урамы автомобиль юлларын җәйге карап тоту;
- Ольгино авылы юллары читендәге үләннәрне чабу

**3. Ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:**

- зират территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын чыгару
- зират территориясендәге үләннәрне чабу ( ГСМ, бензотриммер сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү)
- карт агачларны кисү

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 39 катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 23, бу 58 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен 23 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Ольгино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым чараларын кертергә, моңа гражданнарның түбәндәге категорияләре керми: 1 һәм 2 группа инвалидлар, Әфганстанда, Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, локаль конфликтларда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, түләү кләме 350 ( өч йөз илле сум) сум итеп билгеләнгән көндезге уку формасындагы студентлар, ЛХР һәм ДХРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнар, шулай ук аларның хатыны, балигъ булган балалары, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналары.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлтергә:

**1. Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

- Ольгино авылы буенча урамнарны яктырту, Ольгино авылының Набережная урамы яктырткычларын алмаштыру;
- яктырткычлар сатып алу.

**2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**:

- Ольгино авылының Набережная урамында автомобиль юлларын кышкы карап тоту;
- Ольгино авылының Набережная урамы автомобиль юлларын җәйге карап тоту;
- Ольгино авылы юллары читендәге үләннәрне чабу

**3. Ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү:**

- зират территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын чыгару
- зират территориясендәге үләннәрне чабу ( ГСМ, бензотриммер сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү)
- карт агачларны кисү

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Метрәй җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Метрәй авыл җирлеге башлыгы Шамгунов И.В.